# Мәктәп хәбәрчесе

**№9**
(№60)
ноябрь
2024 ел

*Түбән Майна урта мәктәбе газите*



Тел. 8 (84344) 4-38-46 sch1644maina@mail.ru


***/Мөгаллим киңәше/***

## *Әти тәрбиясе кирәк!*



Бер баладан “Сиңа ике кул нигә кирәк?” – дип сораганнар. Бу бала җавап итеп: “Бер яктан әнинең кулын, икенче яктан әтинекен тотып җитәкләшеп барыр өчен”- дигән. Аның өчен төн йокыларын йокламый, үзе ашамаганны да ашатучы әнисе генә түгел, ә әтисенең дә янәшә булуы, аның белән һәрчак бергә атлап баруы да мөһим икән әле сабыйга.Тик бүгенге көндә “әтиләребез” балаларының бу теләкләрен канәгатьләндерә аламы икән соң? Тигез гаиләдә үсеп тә, балалар үзләрен ялгыз хис итмиләрме? Җәбер-золымнардан саклап, күркәм үрнәк күрсәтә беләме аларга әтиләре?

Ир-ат элек-электән җаваплылыкны, кыен мәсьәләләрне хәл итүне үз өстенә алуы белән аерылып торган. Баланың яшь үзенчәлеген искә алып, хезмәт тәрбиясе бирү, аны кыенлыкларны җиңәргә өйрәтү, спортка тарту зур әһәмияткә ия. Аң-белем алу, фикерләү сәләтен үстерү, уен эшчәнлеге белән шөгыльләнү дә мөһим. Бала һәрвакыт әзергә генә риза булып яшәргә күнекмәсен. Үсеп килүче шәхеснең эшенең нәтиҗәсе генә түгел, ә аның барышы да кызыксындыра. Балаларның барлык ихтыяҗларын бернинди каршылыксыз канәгатьләндерү, аның үзендәге уңай сыйфатларын югалтуга китерә.

Бала кечкенә вакытта ата-анасына охшарга тырыша, алардагы сыйфатларны үзендә булдырырга тели (әтиләрдән, гадәттә, ир бала үрнәк ала). Әхлаксызлык, эчкечелек, гаугалы булу, сөйләмдә әдәпсез сүзләр куллану кебек тискәре сыйфатлар баланың рәхимсез, мәрхәмәтсез, усал булып үсүенә зур йогынты ясарга мөмкин. Әти кешенең сабырлыгы, һәр сүзне уйлап, төпле итеп әйтүе, эш-гамәлләренә җаваплы, итагатьле булуы ир бала өчен үрнәк сыйфатлар булып тора. Бала сезнең һәрвакыт эш белән мәшгуль булуыгызны күреп торсын. Аның сезнең белән бергә һәр эшкә катнашуы мөһим. Шуны ассызыклап әйтергә кирәк: ир баланы файдалы хезмәткә күнектерү – иң әһәмиятле мәсьәлә.

Ир-ат яңалыкка, яңа ачышлар ясарга омтылучан. Шуңа күрә һәр ир бала киләчәктәге юлын яшьтән үк сайларга тиеш. Спорт белән шөгыльләнү аңа үзенең нәрсәгә сәләтле булуын аңларга ярдәм итә. Малайларның һәрберсенең йөзеп тә, очып та, көрәшеп тә карыйсы килә. Әгәр андый мөмкинлек булмаса, ул үзен хокук тәртибе кагыйдәләренә туры килми торган, әхлаксыз гамәлләр кылуда сынап карарга омтылырга мөмкин. Баланы төрле көндәлек мәшәкатьләрдән, бурычлардан азат итәргә, аңа һәрдаим ярдәм итәргә тырышырга киңәш ителми. Алда торган һәр мәсьәләне кемдер хәл иткән очракта баланың тормыш, табигать, кешеләр белән кызыксынуы кими. Шул ук вакытта аның кайда һәм кем белән аралашуын белеп белеп тору мөһим. Ул үзенең янәшәсендә аңа кыен вакытта һәрвакыт ярдәм кулы сузарга әзер торучы булуын тоярга тиеш.*(Дәвамы икенче биттә)*

*(Дәвамы икенче биттә)*

## *Әниләр көне белән!*

***Әниләрне тиңләр идем***
***Күктәге йолдызларга***
***Янып торып йөрәкләргә***
***Маяк булганга күрә.***
***Тиңләр идем әниләрне***
***Чәчәкле болыннарга.***
***Күңеле белән гаиләгә***
***Матурлык тудырганга.***
***Тиңләр идем әниләрне***
***Дулкынлы диңгезләргә***
***Тормыш эчендә курыкмый***
***Йөзәргә өйрәткәнгә.***
***Тиңләр идем әниләрне***
***Төнге ай яктысына***
***Караңгыда адаштырмый***
***Туры юл күрсәткәнгә.***
***Ничек кенә тиңләсәм дә***
***Сыйфатлар табыла тора.***
***Әти янәшә булганга***
***Әни шундый бай була.***




Кадерле әниләребез! Сезне Әниләр көне белән котлыйбыз! Сезгә рухи көч, тормыш зирәклеге, фәрештә сабырлыгы, хатын-кыз бәхете, өйләрегез нурлы булуын телибез. Һәрвакыт һәм һәркайда үзегезне кирәкле һәм сөекле кеше итеп хис итегез. Сез бит җирдә иң газиз, иң якын кеше. Сезгә багышлап нинди генә сүзләр язсак та, көнделдәгене әйтеп бетерեп булмас төсле. Әни дигән сүзгә күпме сыйфат сыйганын яраткан кызыгыз, улыгыз гына белә. Әниле булып һәр балага яратуда, назда коенып үсәргә насыйп булсын. Әти белән бергә көчле булып озак яшәвегезне телибез.

*Бәйрәмегез белән котлап,*
*барлык укучылар исеменнән,*
*“Мәктәп хәбәрчесе”редколлегиясе*

***/Безнең уңышлар/***



23 ноябрь көнне 11 сыйныф укучысы **Нурматова Зәйнәп** Казан шәһәренең Россия герое А.В.Козин исемендәге 7 нче номерлы гимназия базасында үткәрелгән Л.Н.Толстой исемендәге XXII республика фәнни-гамәли конференциясендә катнашты ."В.П.Астафьев – певец родной деревни" дигән фәнни эшен яклап, 3 нче дәрәҗәдәге дипломга лаек булды. Зәйнәпне зур җиңүе белән тәбрик итәбез. Аңарга зурдан-зур уңышлар теләп калабыз.

***/Укучылар иҗаты/***

## *Малай һәм аның дүрт аяклы дуслары*

Бер кечкенә малай мәктәпкә барганда аңа гел этләр очрый торган булган. Малай ул этләрне кызганып, әнисе биреп җибәргән ипине сумкасыннан алып аларга ашаткан. Шуның өчен дүрт аяклы дуслары аны көн саен шатланып каршы алганнар һәм озатып калганнар.

Бер көнне малай мәктәптән кайтканда аның каршысына төлке килеп чыккан. Аны куркытырга теләп малай кычкырып караса да, төлке китергә ашыкмаган. Шул вакыт малайның тавышын ишетеп аның дүрт аяклы дуслары килеп җиткәннәр. Алар төлкене урманына кадәр куганнар.

Яхшылык җирдә ятмый шул. Малайның эшләгән яхшылыгы үзенә кире кайткан.

***Халит Галиуллин, V сыйныф укучысы***

---

## *Сәяхәтче һәм эт*

Борын-борын заманда яшәгән, ди бер сәяхәтче. Ул бик күп җирләрне гизеп, күп халәрне күреп йөргән, ди. Шулай йөри торгач, көннәрдән бер көнне, ул сөйләшә белә торган эт белән очрашкан. Ләкин сәяхәтчегә ул эт бер дә ошамаган. Чөнки ул матур итеп сөйләшә белгән, ә безнең сәяхәтче тел байлыгы бик сай икән.

Сөйләшә белгән эттән көнләшеп, сәяхәтче аңа тозак корырга булган. Төнлә белән торып чокыр казыган. Чокырның өстен агач ботаклары, кипкән яфраклар белән каплап куйган. Икенче көнне ул эткә бергә сәяхәт итәргә тәкъдим иткән. Эт, эшнең нәрсәдә икәнен белмәгәнлектән, риза булган.


Эш пеште дигәндә генә сәяхәтче үзе казыган чокырга барып та төшкән. Дөрес әйткән шул бабайлар: кешегә чокыр казыма – үзең төшәрсең.

***Азамат Гыйниятуллин, V сыйныф укучысы***

## *Витаминлы кроссворд*

***/Күңелле тәнәфес/***

1. Крахмалга бай эре бөлбеле яшелчә.
2. Цитруслардан булган җимеш агачы.
3. Көньякта үсә һәм эре җимеш бирә торган мәңге яшел цитрус агачы.
4. Алмагачның җимеше.
5. Роза чәчәклеләр семьялыгыннан сабак төбеннән очлаебрак киткән шар сыман итләч җимеш.
6. Ачы, тәмле тамыразык яшелчә.
7. Күпьеллык үсемлек барлык яшелчәләрдән иртә өлгерә.
8. Маймылның яраткан ризыгы.
9. Арчанчалар семьялыгыннан мәңге яшел ярым куак. Шар сыман куак, түгәрәк күп орлыклы ачы, куе кызыл җиләк.
10. Орлыкларын эчендә саклый торган бердәнбер җимеш.



***Гөлсем Сафиуллина, IV сыйныф укучысы***

**Өстәлдә 6 стакан тора. Өчесе буш, өчесенә су салынган. Ничек итеп сулы һәм буш стаканнарны чиратлаштырырга? Бер генә стаканга тияргә ярый.**



***/Котлыйбыз!/***



Ноябрь аенда дөньяга килгән дусларыбыз **Нурматова Асияне** (V сыйныф), һәм **Гафиятуллин Саматны** (XI сыйныф) туган көннәре белән котлап, ныклы сәламәтлек, укуларында зур уңышларга ирешүләрен телибез.


Газетаны гамәлгә куючы – Түбән Майна урта мәктәбе
Мөхәррир – Фәнүзә Гафиятуллина
Редколлегия әгъзалары: Зәйнәп Нурматова, Самат Гафиятуллин, Кәүсәр Насыйрова, Ләйсән Закирова, Мәдинә Әхсәнова, Камил Төхвәтуллин

## Тәрбия чаралары /Мәктәп тормышы/



4нче ноябрь – **Халыклар бердәмлеге көне** тирән рухи мәгънәгә ия. Ул безне бердәм булырга, ата-бабаларыбызның каһарманлыгын хөрмәт итәргә өйрәтә. Бу бәйрәмне балалар кечкенәдән белеп үсәргә тиеш. Шул уңайдан укучылар өчен "Халыклар бердәмлеге көненә" багышланган әңгәмә узды. Балаларыбыз безнең республикабызда төрле милләт халыклары: татарлар, руслар, чуашлар, марилар, башкортлар һ.б яшәгәнен белеп, бергәләп күңел ачып, матур бәйрәмнәр уздырганнарын сөйләдек.

*8нче ноябрьдә **Россия Федерациясе Эчке эшләр органнары хезмәткәрләренең хезмәт бурычларын үтәгәндә һәлак булганнарны искә алу көне** билгеләп үтелә. Югары сыйныф укучылары өчен тәрбия эшләре буенча киңәшче Олеся апа белән берлектә сыйныф җитәкчеләре «Буыннан буынга. Хәтердә» дигән хәтер сәгате үткәрделәр.*




20нче ноябрьдә **Халыкара бала көне, Бала хокукларын яклау көне** билгеләп үтелә. Бу дата очраклы рәвештә сайланмаган. Ул 1959нчы елда нәкъ менә шул көнне Бала хокуклары декларациясе кабул ителүе белән игътибарга лаек. Документның төп максаты «Балаларга бәхетле балачак тәэмин итү». Бу көнгә багышланган чаралар 6-7нче сыйныфларда узды.

Шул ук көнне Нюрнберг процессына багышланган сыйныф сәгатьләре үткәрелде. **Нюрнбергпроцессы** – XX гасырның төп суды. Ул Икенче Бөтендөнья сугышы вакытында хәрби җинаятьләр кылган Германия фашистлары һәм аларның иярченнәрен хөкем итү өчен оештырыла. Әлеге суд процессы 1945 елның 20нче ноябреннән 1946 елның 1нче октябренә кадәр ел буе диярлек дәвам иткән. Бу вакыт эчендә дүрт илдән сигез судья 403 ачык утырыш һәм 216 суд тыңлаулары үткәрә. Аларда 300000 язма күрсәтмә укыла һәм 240 шаһит тыңлана. Суд утырышлары беркетмәсе 16000 бит тәшкил иткән. Нюрнберг процессы – тарихта беренче тапкыр кешелеккә каршы җинаятьләрне гаепләгән беренче Халыкара җинаять трибуналы булып тора.




29нчы һәм 30нчы ноябрьдә дәүләт символларына багышланган чаралар узды. 1991нче елның 29нчы ноябре – **Татарстан флагының туган көне**. 1993нче елның 30 ноябре – **Россия гербы расланган көн**. Бөтен мәктәпләрдә дә дәүләт символлары һәм туган тел турында чаралар еш булырга тиеш. Россия флагы, Россия гербы, гимны, Татарстан флагы, гербы, гимны һәм «Туган тел» җыры. Илне, халыкны, мәдәниятне ихтирам итү дәүләт символларын хөрмәт итүдән башлана.



21нче ноябрендә **Бөтендөнья юл-транспорт һәлакәтләре корбаннарын искә алу көне** билгеләп үтелә. Бөтендөнья юл-транспорт һәлакәтләре корбаннарын искә алу көненең төп максаты – җәмәгатьчелек игътибарын юлларда куркынычсызлык проблемаларына юнәлтү, юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә үлем һәм җәрәхәтләнү очракларын киметү, юл хәрәкәтендә катнашучыларның, шул исәптән мәктәп укучыларының да үз-үзен юлда тоту культурасын күтәрү дә булып тора. Бу дата — иң элек, юл хәрәкәтендә катнашучыларның барысына да юлның чиксез игътибар һәм саклык таләп итүен искә төшерү. Юл-транспорт һәлакәтенең корбаннары олылар гына түгел, балалар да булуын белеп, мәктәбебездә ЮИД түгәрәге җитәкчесе Рифкат абый Туктамышев әлеге көнгә багышланган чара уздырды. Укучылар өчен презентация тәкъдим ителде, тема буенча сорауларга җаваплар бирелде. Түгәрәккә йөрүче балалар үзләреюлга чыгып, рейдлар уздырдылар.

***Ләйсән Закирова, VII сыйныф укучысы***

---

***(Башы беренче биттә)****Әтиләр! Малайлар – тынгысыз, тиктормас халык. Аларның сезне шатландырган вакытлары, кәефегезне төшергән чаклары була. Шуңа да улыгыз чын ир-егет булып үсеп җитсен өчен, сездән зур хезмәт, таләпчәнлек, түземлек, үзара аңлашып яшәүгә иреешү сорала. Балагыз белән күбрәк булырга тырышыгыз. Аның белән көндәлек аралашканда батырлык, иптәшлек, намус турында сөйләргә сәбәпләр күп табыла. Балаларга игътибарлы булыйк, әйтергә теләгән сүзләре булса, тыңларга вакыт табыйк, үгет-нәсыйхәт, киңәшләребезне бирик. Без аларга ачык чырай, көләч йөз белән карасак, алар да безгә йөрәкләрен ачарлар. Ягымлы карашны алар читтән түгел, бездән күрсеннәр иде. Балалар урам тәрбиясе түгел, ә гаилә җылысы күреп үссеннәр.

***Сирин Камалова, башлангыч сыйныф укытучысы***

## Мәктәптә гаилә бәйрәме /Безнең бәйрәмнәр/



Гаилә гомер-гомергә яшәешнең башлангычы булды. Гаилә – кешенең төп тереге, җәмгыятьнең рухи сәламәтлеге чыганагы. Гаилә – ул җылылык, мәхәббәт, ышаныч учагы. Аның төп бурычы – балалар үстерү, аларга лаеклы тәрбия һәм белем бирү, тормышта үз юлларын табарга өйрәтү. 2024 ел юкка гына Гаилә елы дип игълан ителмәде. Шул уңайдан мәктәбебездә**"Мин гаиләм белән бәхетле"** дип аталган чара оештырылды. Бу чараның төп геройлары үзара ярышучы гаилә парлары һәм аларның балалары булды. Монда Сафиуллиннар, Хәбибрахмановлар, Гыйниятуллиннар, Җамалетдиновлар гаиләләре катнашты. Ярышучыларыбыз төрле иҗади, тормышчан, психологик биремнәрне бик җитез һәм төгәл үтәделәр. Аларны сынап, күзәтеп утыручы әти-әниләр дә, балалар да буш утырмады, әлбәттә. Балалар өчен төрле кызыклы уеннар, әлкәннәр өчен конкурслар оештырылды. Бу очрашу үсеп килүче буынга көчле һәм тату гаилә булып яшәргә кирәклеген күрсәтте.

***Гөлшат Закирова, башлангыч сыйныф укытучысы***

---

## Театрга бардык /Безнең сәяхәтләр/



Пушкин картасы биргән мөмкинлекләрне һәрдаим файдаланырга тырышабыз. Шул исәптән чыгып, 28нче ноябрьдә укучыларыбыз Казан шәһәренә сәяхәт кылдылар. Габдулла Кариев исемендәге театр бинасына әле беренче тапкыр баруыбыз иде. Тамаша сәгать көндезге бердә генә башланганлыктан, Казанга килеп җитүгә иң элек төшке ашны ашадык. Аннан яңашәдәге "Туган авылым" ял комплексына кереп, андагы биналарны күзәтеп, матурлыкларга сокланып йөрдек. Күбебез киләчәктә шундый агач өйләрдә яшәргә дә хыялланды. Матурлыкны тудыру табигатьтән башка булмаганлыгын аңладык. Кеше күңеленә табигатькә якынлык хас булганга, агач эшләнмәләр шундый соклану тудыргандыр.

**Габдулла Кариев исемендәге театр** бинасында Илфак Хафизов һәм Ренат Абяновның **"Тау битендә Сабантуй"** тамашасы куелды. Бу күренеш авыл сабантуйларының ярлылануын күрсәтүгә багышланган иде. Элеккеге йолалар югалган, кеше белән табигать бәйләнеше өзелгән, кеше хиссезгә әверелгән замана шаукымын тасвирлады бу тамаша. Чынлап та, без хәзер матурлыкны да күрә белми торган, кыйммәтләр алмашынган заманда яшибез. Артистлар да автор әйтергә теләгән фикерне бик оста итеп күрсәттеләр. Ат, тавык булып уйнаучылар да, төрле йорт хайваннарын тасвирлап чыгыш ясаучылар да, рольләрен җиренә җиткерделәр. Хайваннар холкын үз кыяфәтләренә чыгарып уйнарга күпме тырышлык һәм осталык кирәк. Без бит телефон экраннын гына күрергә өйрәнеп беткән буын. Монда аларның уйнаулары безне авыл баласы иканлегебезне искә төшерде кебек. Бу театрда булуыбыз безнең күңелдә яхшы эз калдырыр, дип ышанасы килә.



Сәяхәтебезне оештырып алып барган укытучыларга зур рәхмәтебезне белдерәбез. Тагын да матур, эчтәлекле чараларны күрергә теләп калабыз.

***Настя Сафеева, VII сыйныф укучысы***

---

## Республикакүләм шахмат турниры нәтиҗәләре /Безнең спорт/



22-24 ноябрь көннәрендә Казанда шахмат буенча **Рәшит Нәҗметдинов исемендәге Татарстан Республикасы команда чемпионаты** узды. Турнирда республиканың шәһәр һәм районнарыннан 45 команда катнашты, алар арасында Аксубай районы командасы да бар иде. Аксубай команда составына Магизов Тимур, Гафиятуллин Фаил, Крайнов Тимур һәм Гафиятов Илнар керде. Команданың тренеры – Горбунов Геннадий.

Турнир Швейцария системасы буенча узды. Алты уен нәтиҗәләре буенча безнең команда турнир финалына чыкты. Анда көчле көндәшләре — Балтач районы командасы белән очрашты. Команда бик яхшы уен күрсәтте, әмма бу юлы уңыш көндәшләр ягында булды. Нәтиҗә – республика турнирында икенче урын. Икенче урын – команданың һәр әгъзасының тырышлыгы нәтиҗәсендә ирешелгән бик югары нәтиҗә. Бигрәк тә безнең укучыбыз **Гафиятуллин Фаилне** билгеләп үтәргә кирәк. Чөнки ул безнең командасы өчен иң күп очко җыйды.